

Авыллар… Татар авыллары… Аларда vткән тарихыбызнын бер олеше, халыкнын моны, кайгы-шатлыгы, куанычлары һәм сагышлары. Аларнын кайберләре бик борынгы, икенчеләре шактый сон барлыкка килгән. Һәрберсенен vз vсеш тарихы, vз даирәсе, vз мохите, vзенен данлыклы кешеләре бар…
Милләтне авыл саклар, диләр. Шулай, жәй коне Авыл бәйрәмен Ләмберә районы кечкенә Хаджи авылы vткәрде. Биредә клуб булмаганга, чараны авылнын унжиденче йорты капка алдында уздырдылар.       Шәхси эшмәкәр Шамиль Алләм улы Курмакаев сату жәелдерде, ә Алия Нурый кызы Аитова житәкләгән Кривозерье урта мәктәбе тvгәрәге укучылары кул эшләре кvргәзмәсе оештырды. Тәмле-тәмле татар халык ашларыннан авыз итми калып булмады. Бәйрәмнен спонсорларын да әйтми булдыра алмыйм, алар - Баязит Зиннур улы белән Шамиль Аллям улы Курмакаевлар, Розалия Харис кызы Губейдуллова, Раис Фатых улы Булатов, Камилә Айса кызы Карабанова. Авыл халкы аларга һәм оештыручыларга рәхмәтле.
Матур-матур кунакка йоргән кием-нәрен киенгән халык, алдан ук урындыкларын чирәм буйлап урнаштырып, жыелып утырыштылар һәм бәйрәм башланганчы аралашып та алдылар. Ниһаять, коткән минутлар житте. Ләмберә районы Администрациясендә мәдәният, спорт һәм туризм бvлеге модире Ш.А.Курмакаев тантаналы рәвештә Авыл бәйрәмен ачып жибәрде һәм  Хаджи халкын ихластан котлады. Шамиль Али улы авыл остендә хормәт яулаган, гомерләре буе тырыш хезмәт кvрсәткән Мордовиянен атказанган укытучысы Роза Мингажетдин кызы Рамазановага, хезмәт ветераннары Роза Абдрахман кызы Чуракова белән Сания Летфулла кызы Мангутовага Ләмберә районы Администрациясе Хормәт грамотасы тапшырды. Аннары Хаджи авылы кергән Кырви авыл Администрациясе житәкчесе урынбасары Зульфия Ислам кызы Байбулатова якташларын котлап,  Хормәт грамоталарын Сяит Невмятулла улы Чураков, Линиза Наиль кызы Карабанова һәм Галия Наиль кызы Тимкаевага тантаналы рәвештә бирде. «Хыял» ансамбле, котлау сәләме буларак, яраткан татар жырларыбызны янгыратты.
Һәрбер авылда vз батырлары булган тосле, Хаджида да алар бар. Ул - Боек Ватан сугышы һәм хезмәт ветераннары, «Сугыш балалары», башка локаль сугыш батырлары - оч буын вәкилләре: Наиль Айса улы Карабанов белән Ринат Фатих улы Мангутов, Няим Гаяр улы Чураков белән Газинур Гаяр улы Мусалиев. Гомерләрен, әтиләре vрнәгендә, хәрби хезмәткә багышлаганнарны да онытмадылар: Рамиль Карабанов, Альберт Янгляев һәм Руслан Карабановны котладылар.
Бәйрәмдә авылларынын атаклы кешеләрен искә алу бик тә урынлы булды. Хаджи

авылында туып-vскән Сырмолотовлар һәм Тимкаевлар гаиләләре, Россиянен атказанган тренеры, СССР спорт мастеры Н.Б.Чураков, грек-рим корәше буенча Ленинградның абсолют чемпионы Р.Ф.Тимкаев турында горурланып сойләделәр. Һәм һәрхәлдә, авылда хормәт яулаган олылары турында да сvз барды: 31 августта 91 яшен тутырган Моршидә Фейсхан кызы Мусалеева, 26 октябрьдә шулай ук 91 яшь тулачак Сания Каюм кызы Рамазанова иде. Тырыш хезмәтләре очен рәхмәтле жылы сvзләр янгырады. Барчасына багышлап, Альфия Максимова башкаруында, кvнелләрнен тирән почмагына урнашырлык татар жыры янгырады.
Болай булгач, авылнын ин нәние дә онытылмады. Жылы котлаулар 2013нче елнын 12 октябрендә Альфия белән Равиль Янгляевларнын гаиләсендә туган Таһир исемле улларын тәбрикләделәр. Бергә ярты гасырдан артык гомер итvчеләргә, 55 ел Сәит Невмәтулла улы белән Зәйтvнә Асыйм кызы Чураковларга һәм ин яшь пар - Радик белән Юлия Ишкиняевлар гаиләләренә жылы сvзләр әйтеп, матур-матур теләкләр теләнде бу чарада.
Ә авыл хужалыгында тырышларга, кырларда иген vстерvчеләр, фермада сыер савучылар исеменә ин жылы сvзләр әйтелде. Чирек гасыр сыер сау-ган Румия Абдулла кызы Карабанова, лаеклы ялга кадәр тырышып эшләгән хезмәт ветераны Равилә Хосәен кызы Курмаева бәйрәмдә кадерлеләр рәтендә булдылар. Бvген дә «Курмакаев» фермер хужалыгында хезмәт итvче Баязит белән Рәсим Зиннур уллары Курмакаевлар бvләкләнvчеләр арасында иделәр. Авылдашлары аларны хормәт итә. Алты бала асраган Зыя Низаметдин улы белән Алия Исмаил кызы Карабановларны да бvләкләделәр бу конне.
Бәйрәмнен «йоземе» дә булды. Ул - Уфадан әбисенә кунакка кайткан икенче сыйныф укучысы Алмаз Зайнетдиновнын курайда монлы итеп уйнавы. Тагы яттан сәнгатьле иттереп совет солдатынын немец кызын коткаруы турында һәм батырга куелган Трептов парктагы һәйкәл турында сойләде.
Авыл бәйрәменә әзерлек эшләре арасында конкурслар vткәрv дә каралган иде. Шулай, авылнын ин матур һәм жыештырылган ое иттереп Роза Касим кызы Карабанова йорты аталды. Ә ин оста ипи пешерvче Рәисә Хәмзә кызы Тимкаева булды, ин оста яшелчә vстерvче Алия Нәкыйп кызы Курмакаева иде, ә ин матур чәчәкләр Галия Касим кызы Базееванын бакчасында vсә. «Ин кунакчыл йорт» дип Зыя Низаметдин улы Карабанов гаиләсе аталды. Алар ой алдында горләп Авыл бәйрәме vтте.
Хаджи кешеләре һәм кvнаклар, оештырылган Бәйрәмдә рәхәтләнеп кvнел ачу белән бергә, бик тә кызыклы ярышлар белән уеннарда катнаштылар. Олыларнын корәшләре белән бергә, кечкенәләрнен капчык эчендә йогерvләре мавыктыргыч булды. Тагы гирьләр кvтәрv, армреслинг... Ин кочле булып Хаджи кешесе Рафаиль Свидяков аталды. Ул 16 кг гирьне 100 тапкыр кvтәрде. Икенче урында анын улы Ильдар. Ул 75 тапкыр, ә 40 тапкыр кvтәреп оченчелекне яулаган Бурят Шахидов иде. Армреслингта да әтиле-уллы жинvчеләр иделәр, әмма Ильдар бу очракта – беренче, әтисе – икенче, ә Руслан Зайнетдинов оченчелекне яулады.
Бәйрәм жырсыз булмый. Концертны матурлап Артём Костюк, Альфия Баширова, Иркәм Заликова, Наталия Жигунова, «Русская душа» ансамбле һәм башкалар чыгыш ясадылар. Халык аларны алкышларга кvмде. Кыскасы, Хади авылы кешеләре эшли дә, кvнел дә ача беләләр. Шулай булгач, кечкенә генә авыллар да яши әле.

Наилә Насырова әзерләде